Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Татар Баганалысы авыл җирлеге Советы

КАРАР

2025 елның 18 июне № 59/1

Бишенче чакырылыш
Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Татар Баганалысы авыл җирлеге Советы
депутатларын сайлауларны
билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясы, 2007 елның 7 маендагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 105 статьясындагы 1 өлеше, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Татар Баганалысы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Татар Баганалысы авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Татар Баганалысы авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны 2025 елның 14 сентябренә билгеләргә.
2. Әлеге карарны ул кабул ителгәннән соң биш көннән дә соңга калмыйча билгеләнгән тәртиптә халыкка җиткерергә.

Татар Баганалысы авыл җирлеге
башлыгы Р.Р. Җаббаров